# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в статьи 2 и 4 Закона Республики Татарстан «Об энергосбережении и о повышении энергетической эффективности на территории Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 октября 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 14 июля 2012 года № 49-ЗРТ «Об энергосбережении и о повышении энергетической эффективности на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 7 (I часть) следующие изменения:

1) в статье 2:

а) в пункте 4 части 4 слово «контроля» заменить словами «контроля (надзора)»;

б) дополнить частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Полномочия, предусмотренные пунктом 2 части 4 настоящей статьи, на основании решения органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного осуществлять государственное управление в области энергосбережения и повышения энергетической эффективности, могут осуществляться подведомственным ему государственным (бюджетным или автономным) учреждением, к деятельности которого относится информационное обеспечение мероприятий по энергосбережению и повышению энергетической эффективности.»;

в) часть 6 дополнить пунктом 5 следующего содержания:

«5) осуществление иных полномочий в области энергосбережения и повышения энергетической эффективности, отнесенных Федеральным законом, другими федеральными законами к полномочиям органов местного самоуправления.»;

2) в статье 4:

а) абзац первый изложить в следующей редакции:

«1. Информационное обеспечение мероприятий по энергосбережению и повышению энергетической эффективности на территории Республики Татарстан должно осуществляться уполномоченными органами государственной власти и (или) подведомственными им государственными (бюджетными или автономными) учреждениями, органами местного самоуправления регулярно посредством:»;

б) пункт 5 признать утратившим силу;

в) дополнить частью 2 следующего содержания:

«2. Уполномоченные органы государственной власти и органы местного самоуправления размещают информацию, включенную в государственную информационную систему в области энергосбережения и повышения энергетической эффективности, на официальных сайтах органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» и обновляют ее не реже чем один раз в квартал в соответствии с правилами, утвержденными Правительством Российской Федерации.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
07 ноября 2018 года
№ 84-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында” Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында” 2012 елның 14 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 4 өлешнең 4 пунктында “тикшереп торуын” сүзләрен “тикшереп торуын (күзәтчелеген)” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

“$4^1$. Әлеге статьяның 4 өлешендәге 2 пунктында каралган вәкаләтләр энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы карары белән аңа ведомство буйсынуында булган, эшчәнлегенә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын мәгълүмат ягыннан тәэмин итү кертелгән дәүләт (бюджет яисә автоном) учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.”;

в) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

“5) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә Федераль закон, башка федераль законнар белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән бүтән вәкаләтләрне башкару.”;

2) 4 статьяда:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларын мәгълүмат ягыннан тәэмин итү

дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм (яисә) аларга ведомство буйсынуындагы дәүләт (бюджет яисә автоном) учреждениеләре, җирле үзидарә органнары тарафыннан даими рәвештә түбәндәге юллар белән башкарылырга тиеш:”;

б) 5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

“2. Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм җирле үзидарә органнары энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштыра һәм аны Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган кагыйдәләр нигезендә кимендә кварталга бер тапкыр яңарта.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 07 ноябрь
№ 84-ТРЗ